| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 9 ноябрь № 856

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«2007 елга белем бирү программалары буенча Татарстан Республикасының кече эшмәкәрлек субъектларын укытуны финанслау өчен субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2007 ел, 21 декабрь, 739 нчы;

«2012-2015 елларга Татарстан Республикасының машина төзелеше һәм нефть химиясе комплекслары предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча озак вакытлы максатчан программа проектын әзерләү буенча фәнни-тикшеренү эшен башкаруга оешмалар чыгымнарын каплау өчен 2012 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 24 апрель, 321 нче;

«2013 елда Татарстан Республикасы территориясендә бизнес-проектлар тормышка ашыручы Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтүче оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында» 2013 ел, 28 июнь, 442 нче;

«Юридик затларның 2015 елгы эш йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының берләштерелгән коллегиясен оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 1 март, 126 нчы;

«2016 елда махсус икътисадый зоналарның идарәче компанияләренә резидентлар җәлеп итү эшчәнлеген гамәлгә ашырганда инфраструктура объектларын карап тотуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 18 октябрь, 756 нчы;

«2010 елда «Идел буе федераль округының инвестиция проектларына экспертиза хезмәте (ярдәме) күрсәтү ассоциациясе» коммерциягә карамаган партнерлыгына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1164 нче;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының (алга таба – Программа) «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект чараларын тормышка ашыру өчен гариза бирүче оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1042 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм алар үз көчен югалткан дип санау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инно- вацион икътисады» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 28 июль, 549 нчы карарының 3 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Гарантияләр фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 8 октябрь, 739 нчы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\856.docx